Мөслим районы газетасы
Татарстан Республикасы
Чәршәмбе
№ 91 (11343)
**9 декабрь** 2020 ел
Газета 1931 елдан бирле чыга 16+

# Авыл утлары

**БЕЗ – МӨСЛИМЛЕЛӘР!**
**Сельские огни**

Район яңалыклары – безнең сайтта **www.muslumirc.ru** һәм социаль челтәрләрдә

# Орден геройны тапты

Кичә Бөек Ватан сугышы ветераны Гыйндулла Сәхиповка Кызыл Йолдыз ордены тапшырылды.



Гыйндулла Сәхипов гаиләсе белән. / ЛИЛИЯ ШӘЙМИЕВА ФОТОСЫ.

## Җиңүгә – 75 ел

**Лилия Шәймиева**

**Баек авылында гомер итүче Бөек Ватан сугышы һәм хезмәт ветераны Гыйндулла Сәхипов октябрь аенда 100 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. 8 декабрь көнне гасыр яшьтәше тагын мәртәбәле кунаклар кабул итте. Сәбәбе дә бар – Гыйндулла агага тантаналы шартларда Кызыл Йолдыз орденын тапшырдылар. Йөзъяшәрне котларга ТР вице-премьеры Васыйл Шәйхразиев, ТР хәрби комиссары Сергей Погодин, район башлыгы Рамил Муллин килде.**

– Гыйндулла агага бу бүләк озак еллар һәм ураү юллар аша килеп ирешә. Аның сугыш юлы Иделдән алып Эльба елгасына кадәр сузылган. 1945нче елның 27 июнендә 7нче санлы миномет бригадасы командиры боерыгы белән әлеге зур бүләк ветеранга тапшырылырга тиеш булса да, Гыйндулла ага үзенең бу бүләккә лаек булуын белмичә, кайтып китә. Бүләк хуҗасын эзләп тапты. Ихластан котлыйбыз! Ветеранга тән сихәтлеге, аяз көннәр телибез! – диде Васыйл Шәйхразиев. Ул ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов исеменнән Гыйндулла агага телевизор бүләк итте.

Бөек Ватан сугышы ветераны һәм аның тормыш иптәше Нәҗибә апа бик күп бүләкләр, күчтәнәчләр кабул итте. Ветеранны "Форпост" оешмасы егет-кызлары сәламләде. Аларның тантаналы маршын ветеран тәрәзә аша күзәтте. РФ Үзәк хәрби округы гаскәрләре командующие, генерал-полковник Александр Лапин Гыйндулла Сәхиповны онлайн режимда котлады.

– Данлы сугыш юлы үтеп, авырлыкларга бирешмичә, үзләренең барлыгы белән якыннарына шатлык өләшүче ветераннар – илебез горурлыгы. Кызыл Йолдыз ордены – сезнең батырлыгыгыз өчен күрсәтелгән хөрмәт билгесе ул. 100 яшь тә аз әле сезгә! Тагын 120 яшькә кадәр гомер кичерергә, тормыш иптәшегез һәм балаларыгыз янәшәсендә бәхетле картлыкта яшәргә насыйп булсын! – диде Александр Лапин.

Гыйндулла ага әлеге орденга лаек булуын һаман да белми яшәр иде. Яр Чаллы шәһәренең үзәк район суды судьясы булып эшләүче улы Әгъләә Сәхипов интернет челтәрендә әтисе турындагы мәгълүматка тап була. Ветеран исемендә хәреф хатасы булу сәбәпле, орден кайтканчы тагын бер ел вакыт узып китә.

– Балачагына туры килгән ачлыкны, сугыш елларының утлы газабын, Беренче Украина фронтының 3нче артиллерия дивизиясе миномет полкы составында дошманга каршы көрәшүен онытмый әтиебез. Бу бүләк аңа юкка бирелмәде. Курск дугасындагы каты бәрелешләрдә катнашып, Польша, Чехия, Германия шәһәрләрен азат иткән кеше ул. Миномет командиры һәм заряжающие каты яралангач, әтием Гыйндулла Сәхипов көчле артобстрел вакытында миномөтыннан дошманга каршы ут ача. Шуның белән дошманны юк итүгә ярдәм күрсәтә. Бу – Эльба елгасында булган хәл. Берничә көннән ул минометы белән бер взводка якын фашист автоматчыларын юк итә. Шушы батырлыклары өчен бүләкләнгән әтием! – дип горурлана улы Әгъләә Сәхипов.

Батырлык онытылмый. Айлар, еллар узса да, хәтерләрдә саклана. Гасыр яшьтәшен дә бүләк үзе эзләп тапты бит!

## Хәбәрләр

**Тамчыдан күл җыела**

**Мөслим мөхтәсибәте инвалидлар үнкөнлеге кысаларында матди ярдәм җыю оештырды.**

Барлыгы 22 мең 753 сум акча җыелды. Шуның 5 мең сумы районда үткән хәйрия марафонына тапшырылды. Калган 17 мең 753 сумга 11 мөселман кардәшебезгә азыктөлек пакетлары алынды һәм акчалата ярдәм күрсәтелде. Бу изге эштә катнашучыларның һәммәсенә дә Аллаһ дөньяда да, ахирәттә дә яхшылык бирсен һәм ут газабыннан сакласын, дип хәбәр итәләр район мөхтәсибәтеннән.

**Фән бәйгеләре бара**

**Мәктәп укучылары арасында 12 ноябрьдә башланып киткән фән олимпиадаларының район туры дәвам итә.**

Район мәгариф идарәсеннән алынган мәгълүматларга караганда, кичә 60ка якын укучы физкультурадан теоретик сораулар буенча тест эшләде. Бүген алар җиңел атлетика һәм гимнастика буенча нормативлар тапшыра. Фән бәйгеләре 23 декабрьгә кадәр дәвам итәчәк. Районның бер укучысы 23-25 декабрь көннәрендә мари теле һәм әдәбиятыннан Казанда узачак республика олимпиадасына әзерләнә.

**Күңел җылысын тоеп**

**Район картлар һәм инвалидлар йортында "Күңел җылысын тоеп" исемле чара үтте.**

Картлар һәм инвалидлар интернат-йорты директоры Гөлнар Шакирьянова интернатта яшәүчеләргә матур теләкләрен җиткерде. Аннан соң концерт номерлары күрсәтелде. Учреждение хезмәткәрләре, ирекле волонтер Эльза Хисамиева, "Шәфкать" вокаль ансамбле җырлары, милли биюләр, татар һәм рус телләрендәге җырлар, "Шалтыравык" ансамбле чыгышы һәркемнең кәефен күтәрде.

## Һава торышы

**Чәршәмбе** 9.12 -22 **-16**

**Пәнҗешәмбе** 10.12 -23 **-18**

**Җомга** 11.12 -19 **-18**

**Шимбә** 12.12 -20 **-16**

«Авыл утлары»
№ 91 (11343) | **9 декабрь** 2020 ел



Бу көнне Мөслимдә

## 1985 ел

**7 декабрь**
**Республикада өченче!**

Татарстан АССР Министрлар Советы һәм профсоюзлар өлкә советы терлекчелек биналарын, азык цехларын, ферма җиһазларын һәм социаль-көнкүреш объектларын терлекләрне 1985-1986 еллардагы кышлату чорына үрнәк әзерләү буенча республика смотры йомгакларын карадылар һәм җиңүчеләрне билгеләделәр. Колхозлар һәм совхозлар арасында барган смотрда безнең районның “Урожай” колхозы өченче урынга лаек дип табылды. Хуҗалык ИЖ-2715 автофургоны белән бүләкләнә.

**Үзем тапкан мал түгел**

Электр энергиясен экономияләү максатында быелның 1 ноябреннән республика буенча айлык игълан ителгән иде. Рейд бригадасы берничә оешма һәм хуҗалыкта булды.

М. Вахитов исемендәге колхоз үзәге урнашкан Түбән Табын авылы. Административ бинага керәбез. Күзгә лампочкалардан сибелгән электр яктысы бәрә. Берничә бүлмәнең ишеген ачабыз. Аларда да ут балкып тора. Югыйсә, көн кояшлы, бинаны өстәмә яктыртуның кирәге дә юк.

**Р. Кәрамуллина, “Госэнергонадзор”ның Әлмәт бүлеге инспекторы.**
**Л. Каһарманова, махсус корреспондент.**

**Экономик уку**

Шушы елның 7 декабрендә М. Горький исемендәге колхоз территориясендә хуҗалык җитәкчеләре, партоешма секретарьләре, авыл советы башкарма комитеты председательләре, баш зоотехниклар, баш экономистлар, баш ветеринария врачлары, баш бухгалтерлар, терлек азыгы җитештерү цехы начальниклары һәм партия активы катнашында район экономик мәктәбенең чираттагы занятиесе үтте. Анда катнашучылар Октябрь һәм Сөякәй товарлыклы-сөтчелек, Бәкәбез дуңгызчылык фермаларында булып, кышлату барышы белән таныштылар. Занятиенең теоретик өлеше Октябрь культура йортында үтте.

**Тиешле тәрбия булса**

Менә егерме елга якын инде яшь бозаулар тәрбиялим. Алар аеруча зур кайгырту сорый. Яшь малларны 20 көнлек вакытта кабул итеп алабыз. Һәркайсыбызга кырык һәм аннан да күбрәк баш туры килә. Әле генә аналарыннан аерылып, сөтне чиләктән эчәргә яңа гына өйрәнеп килүче бозауларны чын күңел биреп карамасаң, алар бик тиз авырый, ябыга. Аларны дөрес ашатуга игътибар җитди.

**Ф. Галиева, “Алга” колхозы бозау караучысы.**

***Сәхифәне Мөнирә Арсланова әзерләде.***

# Авыл киләчәге – уңганнар кулында

Җирлегебездә үз эшләрен ачып, уңышлы гына эшләүче фермерлар аз түгел. Әмәкәй авылыннан Ильяс Миннеразыев та шулар рәтендә.

Үзмәшгульлек

**Лилия Шәймиева**

**Авыл хуҗалыгы – тынгысыз хезмәт таләп итә торган тармак. Ильяс Миннеразыевның фермасында 15 тана, сыер һәм үгезләр тәрбияләнә.**

– 2016 елда, дәүләттән 200 мең сум күләмендә ярдәм алып, үз эшемне башладым. Биш сыерыбыз бар иде. Хөкүмәттән алган акчага мал торагы төзедек. Малларыбыз җылы, чиста торакта тәрбияләнә. Авыл кешесе малсыз яши алмый инде. Маллар безнең өчен – төп яшәү чыганагы, – ди Ильяс Миннеразыев.

Кыска гына вакыт эчендә ферма ачу өчен райондашыбызның шактый көч куйганлыгы күренеп тора. “Эш башлаганда әллә ни зур проблемалар белән очрашырга туры килмәде”, – ди фермер.

– Тормыш иптәшемнең гаилә фермасы төзү теләге күптән бар иде. Эш башлагач, җиң сызганып эшләргә кирәк. Үз эшен башларга теләгән кеше моны белеп торырга тиеш. Хуҗалыгында мөгезле эре терлек асраучыларның өстәленнән сөте-каймагы, мае, эремчеге өзелми. Табигый, чиста продукт белән генә тукланабыз, – ди Ильяснең тормыш иптәше Роза.

Ильяс Миргарифан улының фермер булып китүенә дә озак еллар Әмәкәй авыл җирлеге башлыгы булып эшләве сәбәп булгандыр, бәлки. Җирле үзидарәдә хезмәт куйган дәвердә авыл халкының төп яшәү чыганагы авыл хуҗалыгы белән бәйле булуына тагын бер кат инана ул. Һөнәре буенча укытучы булса да, җаны-тәне белән җир кешесе Ильяс Миннеразыев!

– Улыбыз кечкенәдән мал-туар янында үсте. Шәһәр кешесеннән аермалы буларак, авыл кешесе гомер-гомергә күпләп мал тотты, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерде. Ильяс улыбыз да кечкенәдән хуҗалыкта төп ярдәмчебез булды. Әтисе улыбызның үз эшен башлавына, ирешкән уңышларына сөенгән иде. Авылда ихата тотып терлек асраучылар аз түгел, – ди Мәрьям апа.

Әтиләренең ферма ачу теләген шикләнебрәк кабул иткән уллары бүген гаиләнең төп ярдәмчеләре дияргә була. Атна саен кайтып, якыннарына булышып китә егетләр. Берсе Казан химия-технология университетын тәмамлап, Әлмәт шәһәрендә нефть оешмасында хезмәт куя, икенчесе шушы ук уку йортының бишенче курсында белем ала.

Ильяс Миннеразыевның иркен фермасында сыерлар, бозаулар, азык өчен аерым бүлекләр бүленгән. Саву аппаратлары, су, бөртек пешерү өчен аерым бүлмә дә бар. Бина эчтән дә, тыштан да профнастил белән эшләнгән, җылыту өчен заманча материаллар файдаланылган. Салкыннарда да җылы, уңайлы биредә. Төзелешне башыннан азагына кадәр уллары белән башкарып чыкканнар.

– Эшләр өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Печән җыю һәм чабу өчен МТЗ тракторына тагылма җайланмалар бар, пай җиребез дә җитәрлек. Кышка малларга биш тонна фураж, җитәрлек күләмдә печән һәм салам әзерләдек. Азыкны үзебезнең җирлектәге фермерлардан сатып алабыз, – ди Ильяс. Миннеразыевлар җәйге чорда һәр сыердан көнлек уртача 39-43 килограмм сөт савып алганнар. Сөтне Азнакайга тапшырганнар, чөнки бәясе кулай. Хуҗалыкта ике атлары, кош-кортлары да бар. Балалар бакчасында пешекче булып эшләүче Роза – һөнәре буенча бухгалтер. Исәп-хисапны яхшы белгән хәләле авыл тормышының мал-туарсыз бармавын яхшы аңлый.

– Киләчәктә мал санын арттырып, үгезләрне дә күбрәк асрарга планлаштырабыз. Моның өчен Ильяста тырышлык та, теләк тә, үҗәтлек тә җитәрлек! – ди Роза.

Авыллар Ильяс Миннеразыев кебек уңганнар бәрабәренә яши. Ильяс кебекләр арабызда күбрәк булсын иде!

# Эшмәкәрләргә – йөз белән

Эшмәкәрлек

**Лилия Шәймиева**

**ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән республиканың һәр муниципаль районы һәм шәһәр округы территориясендә Эшкуарлар хокукларын яклау буенча ТР Президенты каршындагы вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелек вәкилләре институты оештырылды.**

Җәмәгатьчелек вәкилләре эшкуарларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашырып киләләр, эшкуарлык инициативаларына эксперт ярдәме күрсәтәләр. ТР Президенты каршындагы эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкилнең җәмәгатьчелек вәкиле **Нияз Габдрахманов** белән әңгәмәбез дә шул хакта.

**– Нияз Мөнәвирович, эшмәкәр буларак, сез нәрсә белән шөгыльләнәсез? Бизнеста ничә ел? Үз компаниягез турында сөйләгез әле.**

– 2002 елда мин эшмәкәрлек белән шөгыльләнә башладым. Ул вакытта үз эшемне макарон цехы ачу белән башлап җибәргән идем, шулай ук үземнең тегермәнем эшләде. Шактый гына уңышлы эш алып бардым. Соңыннан минем кул астында “Мөслим-продукт” җәмгыяте үз эшен җәелдерде. “Мөслим күчтәнәче” сәүдә маркасы астында үзебезнең районда, Татарстан һәм күрше республикаларга икмәк-булка эшләнмәләрен реализациялибез. Кондитер эшләнмәләре үзебезнең пекарнядә әзерләнә. Ярымфабрикатлар: манты, пилмән, котлет, голубцы һәм башка итле ризыклар, салатлар да ясыйбыз.

**– Сез ничек җәмәгатьчелек вәкиле булдыгыз? Сезгә нәрсә тәкъдим иттеләр? Җәмәгатьчелек вәкиле буларак, нәрсәгә ирешергә телисез?**

– ТР президенты аппараты аша безнең муниципаль район башлыгына чыктылар. Әлеге вазыйфага мин берсүзсез риза булдым. Ник дигәндә, эшмәкәрләргә ярдәм итәсем килде. Мин аңарчы да җирлегебездә эшләп килгән эшмәкәрләр комитетын җитәкләдем. Ул дәвердә дә эшмәкәрлек мәсьәләләре, килеп туган проблемаларны хәл итәргә туры килде.

**– Вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелек вәкилләре кемнәр алар? Алар эшмәкәрләргә нәрсә белән ярдәм итә ала?**

– Вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелек вәкилләре чиновниклар түгел, ә гамәли эшмәкәрләр, ягъни үзләре эшчәнлек алып баралар. Аларга бизнеста булган проблемалар ят түгел һәм бу проблемаларны хәл итү юлларын алар бик яхшы белә, булган мәгълүматны җитәкчелеккә җиткерә ала. Без вәкаләтле вәкилнең ярдәмчеләре.

**– Нияз Мөнәвирович, безнең җирлектәге эшмәкәрләрнең нинди проблемалары бар? Җәмәгатьчелек вәкиле буларак, нинди мәсьәләләрне хәл итә алдыгыз?**

– Җитди сораулар белән мөрәҗәгать итүчеләр булмады. Ике тапкыр телдән мөрәҗәгать булды, икесе дә Мөслим районыннан. Бер очракта юридик консультация бирелде. Икенче очракта район Башкарма комитеты белән берлектә чаралар билгеләнде.

**– Республика бизнес-омбудсмены соңгы айларда нәрсә белән ярдәм итте? Эшмәкәрләр сезгә нинди сораулар белән мөрәҗәгать итә ала?**

– ТР Икътисад министрлыгында эшмәкәрләргә ярдәм итү буенча аерым бүлек эшләсә, безнең институтта да шундый ярдәм күрсәтелә. Бизнес-омбудсмен



Нияз Габдрахманов./ ФОТО – “МӨСЛИМ-ИНФОРМ” АРХИВЫННАН.

эшмәкәрләргә үз эшләрен алып барганда, проектларын гамәлгә ашырганда яисә судта юридик ярдәм кирәк булганда булышлык күрсәтә.

**– Алга таба нинди планнарыгыз бар? Җәмәгатьчелек вәкилләре институтын камилләштерү буенча нинди инициативалар һәм тәкъдимнәр кертер идегез?**

– Алга таба үз продукциямне сату географиясен һәм продукция төрләрен киңәйтәсем килә. Җәмәгатьчелек вәкилләре институтын камилләштерүгә тукталсак, атнаның һәр чәршәмбесендә 10.00-15.00 сәгатьләрдә эшмәкәрләрне кабул итү оештырылачак. Безнең адрес: Мөслим авылы, Шашин урамы, 2 йорт. Тел: 89173998806. ТР Президенты каршындагы эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкилнең җәмәгатьчелек вәкиленең тагын бер өстенлекле ягы бар – эшмәкәрләрдән актуаль сораулар керсә, республика президентына турыдан-туры чыгып, әлеге мәсьәләне хәл итү юлларын табарга булышачакбыз.

# Өстәмә белемгә өстән карамыйк

Район мәктәпләрендә 2 меңнән артык бала белем ала. Шуларның 82 проценты өстәмә белем алу өчен төрле түгәрәкләрдә, берләшмәләрдә шөгыльләнә.

Мәгариф

**Римма Афзалова**

**Түгәрәкләргә йөреп, балалар белемнәрен ныгыта, кул эшләренә өйрәнә, дөньяны танып белү буенча гыйлемен арттыра. Район буенча 402 бала – ике, 61 бала өч түгәрәккә йөри. Бер генә түгәрәккә йөрүчеләр бар. 285 бала түгәрәкләргә бөтенләй йөрми. Әлеге саннар район башлыгы катнашында узган киңәшмәдә яңгырады.**



Лилия Шәймиева фотосы.

Балалар сәнгать мәктәбендә җиде бүлектә 372 бала шөгыльләнә. Спорт мәктәбенә 474 бала йөри. Мәктәптән тыш эшләр үзәгендә җиде юнәлештә 259 бала шөгыльләнә. Район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча урынбасары Марина Бәдретдинова түгәрәкләрнең балаларны куплап җыя алмавына һәм укучыларның даими шөгыльләнмәвенә борчыла.

Алда телгә алынган өстәмә белем бирү учреждениеләреннән тыш мәдәният бүлегендә – махсус берләшмәләр, мәктәпләрдә аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүгә нигезләнгән түгәрәкләр эшли. Кыскача әйткәндә, сайлап алу мөмкинлеге зур. Шуңа кайсы да булса юнәлештә балаларның аз булуына гаҗәпләнергә дә кирәкмидер, бәлки. Икенче яктан, бала үзе өчен кызыклы өлкәне сайлый. Кемдер спортка гашыйк, кайберәүләр сәнгатьне үз итә. Фән юлыннан китүче балалар да аз түгел.

Өстәмә белем алу балалардан гына түгел, әти-әниләрдән дә тора. Чөнки кечкенә балаларны уку йортына илтеп куярга, барып алырга кирәк. Һәр әти-әнинең дә моңа мөмкинлеге, вакыты булмаска мөмкин. Кайбер балалар, өстәмә шөгыльләнергә теләсә дә, түгәрәкләрнең эш сәгате бер вакытка туры килү сәбәпле, икенче юнәлештән баш тартырга мәҗбүр. Авыллардан йөреп укучы балаларга түгәрәкләрдә шөгыльләнү өчен вакыт та җитмидер.

Ә дәресләрдән тыш, өстәмә шөгыльләнүче балаларның нәтиҗәләре куанырлык. Спортта, сәнгать өлкәсендә егет-кызлар җиңүләре белән сөендерә. Яшьләр белән эшләү һәм спорт бүлеге җитәкчесе Илшат Яббаров китергән мисаллардан күренгәнчә, спорт мәктәбендә 2010 ел белән чагыштырганда спорт төрләре арткан (2010 елда – биш, 2020 елда – унбер юнәлеш). Җиңүләр саны да арта. “Спортның кайсы төрен алсак та, республикада гына түгел, Россиякүләм, хәтта дөнья беренчелегеннән призлы урыннар белән кайткан егет-кызлар бар”, – ди Илшат Яббаров.

Марина Бәдретдинова өстәмә белем алуга күбрәк баланы җәлеп итәргә чакыра. Ул кайбер мәгариф хезмәткәрләренең моңа өстәмә эш итеп кенә каравына борчылуын белдерде һәм мәгариф хезмәткәрләрен, шулай ук төрле ведомстволарны кулга-кул тотынып эшләргә чакырды. Бу очракта баланың түгәрәкләргә ничек йөрүен күзәтеп булачак.

## Газетага язылсаң, бүләк отарсың

Әбунә – 2020

**2021нче елның беренче яртыеллыгы өчен “Авыл утлары” һәм “Сельские огни” газеталарына язылу кампаниясе тәмамланырга санаулы гына көннәр калып килә.**

Почта бүлекчәләренә яки хат ташучыларга мөрәҗәгать итәргә ашыгыгыз! “Мөслиминформ” 2021нче елның беренче яртыеллыгы өчен район газетасына язылучылар арасында бүләкләр уйнатачак. Подписка планын арттырып үтәгән почта бүлекчәләрен дә бүләкләячәкбез.

2021нче елның беренче яртыеллыгы өчен “Авыл утлары” газетасына язылу бәясе – 873 сум. Альтернатив подписка – 498 сум. 13 декабрьгә кадәр Әбунәче үнкөнлеге баруын да онытмагыз. Әбунәче үнкөнлегендә “Авыл утлары”на – 807,6 сумга, “Сельские огни” газетасына 738 сум 30 тиенгә язылырга мөмкин. Реклама 16+



Динар Нуретдинов фотосы.

Сораштыру

## Китап укыйсызмы?

**Узган гасырда безнең ил китап укучылары белән горурлана алган. Китап, әдәби журналларны кулына алмаган кеше сирәк булгандыр. Китапханәләр, китап кибетләре гөрләп эшләде. Хәзер китап укучылар өчен мөмкинлекләр киңәйде, китапханәгә яисә кибеткә барып та торасы юк: яраткан әсәреңне кулыңдагы телефоннан укый яисә тыңлый аласың. Сез китап, әдәби әсәрләр укыйсызмы?**

**Айсылу Мадьярова,**
**район үзәк китапханәсе директоры:**

– Райондашларыбыз китап укый. Китапханәнең ачылу вакытына ук килеп җитүче китап сөючеләребез дә бар. Гадәттә, иртәнге якта өлкәннәр килә, төштән соң мәктәп укучылары, студентлар ача китапханә ишеген. Бүгенге көндә кайберәүләр дистанцион рәвештә белем ала, кайберәүләр диплом эшләре яза. Андыйлар кирәкле китапларын сорап мөрәҗәгать итә. Үзебездә булмаса, китапханәара абонемент аша соратып кайтартабыз. Өлкәннәр күбрәк татарча китапларны укый. Яшьләр классик әсәрләр белән кызыксына, чит ил әдәбияты укый.

**Рәзилә Зарипова,**
**Красноярь:**

– Бу көннәрдә Нәбирә Гыйматдинованың “Үлмәс” исемле яңа әсәрен укып чыктым. Хәзер Хәния Фәрхи турында укыйм. Айгөл Әхмәтгалиеваның “Хәния” исемле бу китабын кемдер сатып алган, үзе укыгач, китапханәгә биреп торган, башкалар да укысын, дип. Элек бик күп укый идем, соңгы вакытта пассивлаштым әле. Балаларны укырга ярата димәс идем.

**Флиза Латыйпова,**
**Симәк:**

– Симәктә минем кебек китап укучы юктыр ул. Бәләкәйдән үк укырга яраттым. Мәктәптә укыганда китап алырга килгәндә китапханә бикле булса, укыган китапларны ишеккә кыстырып китә идек, ә китапханәче безгә дигән китапларны кыстырып куйган булыр иде. Сигезенче сыйныфта имтиханга әзерләнәсе урында качып кына “Алтын йолдыз” романын укып утырганым истә. И орышкан иде инде әни шуны күргәч. Әниемә хәзер 82 яшь. Шулай ук китап укырга ярата. Китапханәгә барып та ала, китапханәче Резида китереп тә бирә. Лениза апам да китап укыды, хәзер дә укый. Барыбыз да яратабыз укырга. Телевизор караганчы, китап укыйм. Китапханәгә барган саен 5-6 китап алып кайтам. Китапханәчебез әзерләп тә куя. Оныкларны гына замана бозды, бик укымыйлар.

**Рүзилә Нәсифуллина,**
**Мәлләтамак авылы китапханәчесе:**

– Кыш көне китап укучыларыбыз аеруча активлаша. Бакчада эшләр тәмамлангач, ихата мәшәкатьләре кимегәч, авыл кешесе рухи азык туплый башлый. Өлкәннәр, укытучылар, тәрбиячеләр китапханәгә еш килә. Венера Нуриева, Сәрия Галиева, Тәнзилә Нигъмәтуллина – иң күп китап укучылардан. Балаларда китап укуга кызыксынуны уяту, тәрбияләү һәм үстерү максатыннан төрле конкурслар оештырабыз. Бу чорда мондый конкурслар он-лайн форматта үтте. Иң күп “лайк”лар алучылар җиңүче булды. Ике ай дәвамында “Иң күп китап укучы гаилә” конкурсы барачак. Җиңүчеләр укылган китаплар саны буенча билгеләнеп, Яңа ел бал-маскарадында бүләкләнер, дип планлаштырдык.

**Сораштыруны Мөнирә Арсланова үткәрде.**




Фото – Pixabay.com

«Авыл утлары»
№ 91 (11343) | 9 декабрь 2020 ел

Яңалыкларны беренче булып
www.muslumirc.ru сайтында укыгыз

# Биш медаль алып кайттылар

Идел буе федераль округы беренчелегенә армрестлинг ярышларыннан мөслимлеләр дүрт алтын һәм бер көмеш медаль белән кайтты.

Лилия Шәймиева

**Районадашларыбыз спорт дөньясында колачлап йөзә. Ярышлардан буш кул белән кайтканнары юк. 25-29 ноябрь көннәрендә Түбән Новгород шәһәренең "Яңа буын" спорт комплексында Идел буе федераль округы беренчелегенә армрестлинг ярышлары узды. Анда ун республикадан 100дән артык спортчы катнашты.**

– Укучыларымның уңышларына ихластан сөенәм. Бу – безнең уртак җиңүебез! Мөслимебезнең җиңүе дип кабул итәм мин моны. Даими төстә шөгыльләнүләр, үз өстеңдә эшләү, тренировкаларны калдырмауның бәясе медальләр, мактау сүзләре булып үзеңә әйләнеп кайта. Укучыларым моны яхшы аңлый. Бу ярышлардан без дүрт алтын һәм бер көмеш медаль белән кайттык, – ди тренер Ларис Бариев.

Мөслим мәктәпләренең 8-9 сыйныф укучылары Әмир Каюмов, Данияр Хәбибуллин, Рамил Ильясов, Айдар Корбыев – алтын, Илина Бариева көмеш медаль яулады. Бүген укучылар Россия беренчелегенә әзерләнә. Ул 2021нче елның 4-8 март көннәрендә Орел шәһәрендә үтәчәк.

– Мондый форматта үтүче ярышларда минем беренче җиңүем. Армрестлинг түгәрәгенә икенче ел гына йөрим. Укуны да, тренировкаларны да алып барыр өчен зур тырышлык, ихтыяр көче кирәк. Тренеры әтием булса да, таләпләр катгый, нагрузка зурдан, – ди Илина.

Пандемиягә бәйле бик күп ярышларны туктаттылар. Соңгы тапкыр Ларис Бариевның укучылары февраль аенда Екатеринбургтан чемпион булып кайтканнар иде. Венгрия һәм Грузиядә үтәчәк бәйгеләргә чакырулы булып та, коронавирус аркасында көчләрен сыный алмый калдылар.

– Киләсе елга планлаштырылган Россия беренчелегеннән җиңү алып кайтырга исәп. Кул көрәше уҗәтләрне үз итә, шушы спорт төрен фанатларча яратучыларга һәрвакыт уңыш елмая. Минем түгәрәккә йөрүче егет-кызларның юлдашы – ихтыяр көче, зур теләк-максатлар. Алга таба да сынатмасыннар иде! – ди Ларис Бариев.



Иң көчле егет-кызлар./ ФОТО – ЛАРИС БАРИЕВНЫҢ ШӘХСИ АРХИВЫННАН.

# Шугалакка килегез!

Лилия Шәймиева



**Кышны олысы-кечесе көтеп ала. Кечкенәдән чаңгы, тимераякта шуарга яратучыларның ел әйләнәсе кыш булуын теләве аңлашыла. 1 декабрьдән Г. Тукай исемендәге Мөслим урта мәктәбе территориясендә рәсми төстә шугалак эшли башлады.**

– Шугалакны ачу тантанасына 300дән артык кеше җыелган иде. Икенче көнне шугалакка 200гә якын кеше килде. Бу арада, көннәр салкын торгач, шуучылар саны берәз кимеде. Көнәнә якынча 60-70 кеше тимераякта шуарга килә, – ди массакүләм спорт һәм мәдәни чаралар дирекциясе җитәкчесе Марат Бәйрханов.

Мәктәп янындагы шугалакта атнаның сишәмбе, җомга һәм шимбә көннәрендә 19.00-20.00 сәгатьләрдә кафе да эшли. Калган көннәрдә будкада дирекция егетләре кизү тора. Тимераякта шуучылар, будкада җылынып, чәй эчеп чыга ала. Тимераякларны прокатка да алырга була. Кечкенәләр өчен 1 сәгатькә прокат 50 сумга төшә, өлкәннәр өчен 100 сум тәшкил итә. Шугалак 17.00-21.00 сәгатьләрдә эшли.

"Яшьлек" спорт комплексы территориясендә дә шугалак ясалды. Анысы спорт түгәрәкләре, тренировкаларга йөрүче хоккейчылар өчен. Җирлегебездәге хоккей командалары, шушы шугалакта күнекмәләр ясап, район һәм республика ярышларына әзерләнә.

– Минем укучыларым – "Яшьлек" командасы егетләре 18 ноябрьдән башлап стадиондагы шугалакка тренировкаларга йөриләр. Балалар спорт киемнәре, кәшәкә, тимераяклар белән тәэмин ителгән. Бик теләп йөриләр. Араларында бик өметле, киләчәктә данлыклы хоккейчы булырлык егетләр бар. Районда спорт белән шөгыльләнү өчен бөтен мөмкинлекләр һәм шартлар тудырылуына сөенәбез. Бүгенге көндә укучылар "Татнефть" кубогына, "Нефть һәм тормыш" журналы призына, бердәм эшче хоккей лигасында үтәчәк ярышларга әзерләнәләр. Командa составында 50дән артык спортчы бар, – ди балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе тренеры Раил Шакирьянов.

Быел, башка еллардан аермалы буларак, "Мөслим йөрәге" скверында да, җәяүлеләр юлы калдырып, шугалак катырыла. Монда теләгән һәркемгә бозда шуу мөмкинлеге булачак.

Михайловка урта мәктәбе ишегалдында быел да шугалак ясарга планлаштыралар.

– Шугалак әллә кайчан әзер булыр иде дә бит, мәктәпнең физкультура укытучысы авырып китте. Озакка сузмый ясарбыз. Безнең авыл халкы спорт чараларында бик актив катнаша. Шугалакны да зарыгып көтәләр. Анда олысы-кечесе яратып шуа, – ди Михайловка авыл җирлеге башлыгы Роберт Исламов.

Кышны алга таба да сагынып көтеп алырлык булсын! Булган мөмкинлекләрдән рәхәтләнеп файдаланып, буш вакытыбызны спортка күбрәк багышлыйк әле!



Фотолар – "Мөслим–информ" архивыннан.

# Язмышларга шулай язылгач...

Язмыш сынаулары һәркемгә дә тигез бирелмәгән. Берәүләр сәламәтлегенең кадерен белмичә, үзләренә хилафлык китерә, икенчеләр авыруларга сер бирмичә яшәргә тырыша.





Илдар Галимов һәм аның гаиләсе. /ЛИЛИЯ ШӘЙМИЕВА ФОТОЛАРЫ.

## Арабызда шундый кешеләр бар

**Лилия Шәймиева**

**Илдар Галимов сау-сәламәт бала булып дөньяга аваз сала. Йөзе елмаюдан балкыган сабый әти-әнисенең иң зур сөенече була. Тик кечкенә вакытта, салкын тиеп, бик еш авырый Илдар.**

– Без озак еллар Казанда яшәдек. Илдарның әтисе белән икебез дә –Саба районыннан. Яшьли шәһәргә китеп төпләндек, – ди әнисе Гүзәл. – Илдар – минем көтеп алган беренче сабыем. Улыбыз кискен респиратор авыру белән еш авырды. Дарулар да күп эчте. Ул чорда башка укол кадыйлар иде. Нигә алай эшләгәннәрдер инде, белмим. Соңыннан, препаратның дозасы артык булып, кан тамырына авырлык килгәндер, диделәр. 1 яше тулганда Илдарның ишетмәгәнен аңладык. Сау-сәламәт балабызны табиблар гына харап итте.

6 яшенә кадәр Илдар Казандагы махсус бакча-интернатка йөри. Аннан начар ишетүче балалар өчен Бөгелмә шәһәрендәге интернат-мәктәптә укый.

– Илдар янына барып йөрдек, ялларга, бәйрәмнәргә өйгә алып кайта идек. 20 яшенә кадәр шушы мәктәптә белем алды, – ди әнисе. – Әлеге мәктәптә Илдар кебек балалар күп иде. Аларның әти-әниләре белән аралашканда шуны белдем: күбесенең сабыйларына кечкенә чакта салкын тигәннән башларына укол ясаганнар. Дөрес кадалмаган укол тискәре нәтиҗәгә китергән.

Мөслимгә Гүзәл апа 1995 елда күченеп кайта. Туганы чакыргач, озак уйлап тормыйча, Мөслим районына кайтып төпләнә. 20 яше тулгач, Бөгелмәдән Илдар да әнисе янына кайта. Кайту белән Мөслим хуҗалыкара төзелеш оешмасына ярдәмче-эшче булып урнаша. Үз тырышлыгы белән кирпеч салырга өйрәнә, акрынлап оста ташчыга әйләнә.

– Илдар сыман үҗәт, тырыш, тынгысыз кешеләр сирәк. Эшне исем өчен түгел, булсынга дип эшли ул. Үз тырышлыгы белән ике катлы йорт җиткереп килә. Бүген өенә газ кертү мәшәкатьләре белән йөри. Хөкүмәт эшеннән кайткач, "шабашкага" йөрергә, аннан үз өендә эшләргә нигек җитешәдер?! Ару-талуны белмәс, ныклы ихтыяр көченә ия, һәрьяклап булган егет Илдар! Өен салганда да, маңгайга беркетелүче фонарь белән яктыртып, инструментларны тешенә кыстырып булса да, берүзе хезмәт куйды. Мондый ир-егеткә ничек сокланмыйсың?! – ди хезмәттәшләре.

Илдарның тормыш иптәше Александра – табиб-педиатр, Ульяновск шәһәре кызы. Илдар белән уртак танышлары аша таныша.

– Беркайчан да саңгырау кешегә кияүгә чыгармын дип уйламаган идем. Язмышыңа нәрсә язылганын белмисең бит. Тәкъдиреңә ни язылган, шул була. Илдар белән гаилә коруыбызга бер тапкыр да үкенгәнем юк. Бик ярдәмчел, гаилә һәм бала җанлыклы кеше ул, – ди Александра Галимова.

Гаилә корып, алты ел матур гомер кичерә алар. Кызлары Әминәгә – дүрт, Заринага ике яшь.

– Без әтине әнигә караганда да ныграк яратабыз. Ул иң әйбәт әти! – ди Әминә.

Әтиләрен өйдә сирәк күргән балаларга әтиләре кунак кебек тоеладыр. Гаиләсе бөтен булсын, җитеш тормышта яшәсен дип, көчен җәлләми эшләгән Илдар кебек ир-егетләр – гаиләнең ныклы тоткалары!

# Яр Чаллының "аяклы энциклопедиясе"

## Синең уларың, Мөслим!

**Алис Мәүлиев Яңа Сәет авылында ишле гаиләдә туа. Гаиләдә – 7 бала. Әтисе Асылгәрәй – балачактан инвалид, тездән бер аягы юк. Яшәүләре җиңел булмагандыр. Балалар хезмәтнең тәмен, икмәкнең кадерен кечкенәдән үк аңлап үсәләр.**

12-13 яшендә Алис такта арба җигелгән ат белән басудан икмәк ташый. 15 яшьтә сыер көтәргә алына. Буе бәләкәй булу сәбәпле, сыерлар таптарлар дип, малайны сарык көтүенә күчерәләр. Яшьтән хезмәткә җигелгән Алис белемгә омтыла. Ләкин урта мәктәптә укыган өчен елына 150 сум акча түләргә кирәк! Гаиләдә андый акча каян булсын?! Урта мәктәпне армиядә тәмамлый ул. Киевта өч ел сапер булып хезмәт итә. Көндәлек хезмәттән соң төнге унбергә кадәр кичке мәктәптә укый.

Хәрби хезмәттән соң Алис Мәүлиев, җиң сызганып, җиде авылны берләштергән "Урожай" колхозында комсомол оешмасы секретаре булып эшли. Бөгелмә индустриаль-педагогия техникумын, Алабуга педагогия институтының техник факультетын тәмамлый.

1972 елдан Алис Асылгәрәй улының тормышы Яр Чаллы шәһәре белән бәйле. Өч ел техник училищеда укыткач, Татарстан Министрлар советының Яр Чаллыдагы хезмәт ресурслары уполномоченные итеп билгеләнә. Ул җитәкләгән идарә бернигә тапкыр исемен алыштыра, эш юнәлешен үзгәртә. 1981 елдан идарә хезмәт һәм социаль мәсьәләләрне хәл итсә, соңрак халыкны социаль яклау дигән изге эшкә керешә. Алис Мәүлиев – Яр Чаллы шәһәренең халыкны социаль яклау эшенә нигез салган кеше, Яр Чаллы социаль яклау идарәсенең беренче җитәкчесе.

Халык өстенә ишелеп төшкән михнәтләр, хезмәт урыннары кыскару, эшсезлек, төрле төбәкләрдә кан коелу, качаклар кайта башлавы – хәлләр кискенләшә башлаганчы ярдәмгә мохтаҗ катлауларны барлау башлана, 1990-95 елларга халыкны социаль яклау программасы төзелә. Сугыш һәм хезмәт ветераннары, Әфган афәтен кичүчеләр, чернобыльчеләр, күпбалалы гаиләләр, инвалидлар – барысы да ярдәмгә мохтаҗ бит! Шул елларда Алис Мәүлиев җитәкчелегендә күп структур подразделениеләр ачыла: сугыш һәм хезмәт ветераннары өчен пансионат, картлар һәм инвалидлар интернат-йорты, инвалидларны тернәкләндерү үзәге һ.б. Шәһәр социаль яклау идарәсе җитәкчесенең эше гаять киңкырлы һәм тынгысыз. Һәр гозерне тыңларга, уйларга, хәл итәргә кирәк. Ярдәм тиешле кешесенә барып җитәргә тиеш.

Үзенә дә, хезмәттәшләренә дә таләпчән, гадел җитәкчене эшендә бик хөрмәт итәләр. Яр Чаллы шәһәр башкарма комитетында аны "аяклы энциклопедия" дип йөртәләр. Нинди генә сораулар белән мөрәҗәгать итмиләр аңа?!

1996 елда Чечен республикасында сугыш барганда Алис Асылгәрәй улын гуманитар колонна башлыгы итеп Чечняга җибәрәләр. Йортҗирсез калган гаиләләр, улларын җирләгән әниләр, әтиәниләрен югалткан ятимнәр, кул-аяксыз калган гарипләр – коточкыч күренеш! Барысы да түземсезлек белән ярдәм көтәләр. Ун КамАЗдан торган автоколонна башлыгы илкгән



Алис Мәүлиев. / ФОТО - МӘҮЛИЕВЛӘРНЕҢ ГАИЛӘ АРХИВЫННАН.

йөкне (азык-төлек, тормыш кирәк-яраклары, кием-салым) качакларга, ятим балаларга, сугышта туйдыручысын югалтканнарга һәм Грозный шәһәрендәге балалар йортына тапшыралар. Ике атна дигәндә Чечняга барган состав исән-сау Яр Чаллыга кайтып керә.

Инде күпме сулар аккан, күпме еллар тарихка күчкән. 80 яшен тутырганда Алис Асылгәрәй улы ныклы нигездә Яр Чаллы халкына социаль яклауны оештырырга алынуы белән горурлана ала. Әлеге фидакарь хезмәте өчен ул Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына да лаек булды.

**Фәнүзә Мәүлиева.**
**Мөслим.**

«Авыл утлары»
№ 91 (11343) | **9 декабрь** 2020 ел



# Тупланма пенсияне билгеләү тәртибе

Пенсия фонды

**Эш бирүчеләрнең иминият түләүләре һәм аларны инвестицияләүдән булган керемнәр хисабына пенсия тупланышын гомер буе ай саен түләү ул тупланма пенсия.**

2015 елның ахырына кадәр сайлау аның файдасына булган очракта 1967 елгы һәм аннан яшьрәк гражданнарның тупланма пенсиясе формалаша ала. Әле яңа гына эшли башлаган һәм иминият түләүләре беренче тапкыр түләнәчәк яшь кешеләрнең хезмәт эшчәнлегенең беренче биш елында пенсия тәэмин итү вариантын сайлау хокукы бар: иминият пенсиясен генә формалаштырыргамы әллә иминият һәм тупланма пенсияләрнеме.

2019 елгы пенсия реформасы пенсия яшен бары тик картлык буенча иминият пенсиясен билгеләү өчен генә үзгәртте. Ә тупланма пенсия өчен (ул кешенең Россия Пенсия фондындагы махсус счетындагы үз тупланмаларыннан түләнә) билгеләү яше үзгәрмәде. Ул элеккечә хатын-кызлар өчен – 55 яшь, ир-атлар өчен – 60 яшь. Пенсия тупланмалары булган кеше картлык буенча иминият пенсиясен көтәргә дә, аларны иртәрәк тә кулланырга хокуклы. Моның өчен ул тиешле яшькә җитүдән тыш билгеле коэффициентка һәм иминият стажына ия булырга тиеш. 2020 елда 11 ел эш стажы һәм коэффициент 18,6 булырга тиеш.

Тупланма пенсияне алуның өч төрле варианты бар: бер тапкыр түләү, срокլы пенсия түләве яисә гомер буена түләү. Бер тапкыр түләү гариза буенча башкарыла. Әмма аның суммасы мондый түләүгә гариза биргән вакытка кешегә тиешле пенсиянең 5 процентыннан артмаска тиеш. Сроклы пенсия түләвен алу вакытын кеше үзе билгели, ләкин ул 10 елдан ким булырга тиеш түгел. Тупланма пенсия гомер буена билгеләнә. Исәпләү өчен пенсия тупланмалары түләү булачак айлар санына бүленә. 2020 елда ул 258 ай тәшкил итә. Мәсәлән, сезнең пенсия фонды счетында 258 мең сум акчагыз булса, тупланма пенсия айга 1 мең сум тәшкил итәчәк. Картлык буенча иминият пенсиясенә хокук барлыкка килгәч, пенсионер ике пенсия – картлык буенча иминият пенсиясе һәм тупланма пенсия алачак.



Фото – Pixabay.com

# Үзмәшгульләрнең пенсия хокуклары

**Үзмәшгуль гражданнар 2020нче елның 1 июленнән һөнәри керемгә салым түләүчеләр сыйфатында салым органнарында теркәлә ала.**

Һөнәри керемгә салымны кулланучы үзмәшгульләрне закон иминият пенсиясенә иминият взнослары түләргә мәҗбүр итми. Әмма РФ пенсия фондына акчав күчерелмәсә, бу хезмәт чоры иминият стажына кертелми һәм шәхси пенси коэффициентлары формалашмый.

Махсус салым режимы кулланучы үзмәшгуль кеше, мәҗбүри пенсия иминияте буенча иреkле рәвештә пенсия фондына иминият взнослары түләп, иминият пенсиясен билгеләү өчен пенсия хокуклары формалаштыра ала. Моның өчен яшәү урыны буенча пенсия бүлегенә гариза тапшырырга яисә Россия Пенсия фонды, Салым хезмәте сайтларындагы шәхси кабинет аша яисә "Мой налог" кушымтасы аша электрон рәвештә мөрәҗәгать итәргә була.

Махсус салым режимы, һөнәри керемгә салымны кулланучы һәм мәҗбүри пенсия иминияте буенча ирекле хокук мөнәсәбәтләренә кергән затлар өчен иминият взносларының минималь күләме билгеләнмәгән. Максималь күләм 2020 елда 256185,60 сумнан артмаска тиеш. Бер ел иминият стажы алу өчен исәп-хисап елында иминият взносының билгеләнгән күләменнән дә аз булмаган сумманы түләргә кирәк. Ул Салым кодексының 430 маддәсе нигезендә билгеләнә (2020 ел өчен – 32023,20 сум). Шулай ук ирекле рәвештә хокук мөнәсәбәтләренә кереп, ел дәвамында исәптә тору шарт. Азрак сумма түләнгән очракта иминият стажына түләнгән суммага тәңгәл чор исәпләнәчәк.

**Мөслим районында клиентларны кабул итү хезмәте.**

# Иминият премиясен кайтаруга хокук турында

Кулланучыга

**2020нче елның 1 сентябрендә "Кулланучылар кредиты (займы) турында"гы Федераль законның 7 һәм 11 маддәләренә һәм "Ипотека (күчемсез милек залогы) турында"гы Федераль законның 9.1 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында"гы 483-ФЗ санлы Федераль закон (27.12.2019) үз көченә керде. Аның нигезендә кредитын вакытыннан алда һәм тулысынча түләгән заем алучы иминият өчен акчаның бер өлешен кайтара ала.**

Шул ук вакытта берьюлы берничә шартны үтәү мөһим: заем алучы кредит һәм заем бурычларын тәэмин итүче ирекле иминият килешүе төзегән булырга; премиянең өлешен кайтару турында гариза биргән булырга тиеш; иминият очрагы билгеләре булган вакыйгалар булмаска тиеш.

Гаризаны иминият компаниясенә яисә банкка (заем алучы аның аша иминиятләнгән булса) җибәрергә мөмкин.

Иминият оешмасы гаризаны алгач, җиде эш көне дәвамында иминиятләү инде гамәлдә булмаган вакыт өчен премиянең өлешен кайтарырга бурычлы. Әлеге яңалык 1 сентябрьдән соң төзелгән иминият килешүләренә карата кулланылачак.

Исегезгә төшерәбез: иминият килешүе төзүгә мәҗбүр итү закон тарафыннан тыелган. Шул ук вакытта бу кагыйдәнең искәрмәсе дә бар: заем алучы килешү буенча залогка салынган милекне (мәсәлән, ипотекада) югалтудан һәм зыян килүдән иминиятләргә бурычлы.

Башка очракларда банк заем алучыга кулланучы кредитының (заемның) альтернатив вариантын тәкъдим итәргә тиеш. Ул кыйммәтрәк булырга мөмкин (югары процент ставкасы белән).

Моннан тыш иминиятләү хезмәте мәҗбүри тагылган булса һәм рәсмиләштергән вакытта банк хезмәткәрен иминиятләүнең кирәк түгеллегендә инандырып булмаса, кулланучы килешү төзегәннән соң 14 көн эчендә мондый хезмәттән баш тартырга хокуклы.

**Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең ТР буенча идарәсенең территориаль бүлеге.**

# Барлык илләргә дә кагыла

Кеше һәм закон

**Коррупция – катлаулы социаль, сәяси һәм икътисадый күренеш. Ул күпмедер дәрәҗәдә барлык илләргә дә кагыла.**

Нәкъ менә коррупция демократик институтларның җимерелүенә, икътисадый үсешнең акрынаюына китерә, еш кына дәүләт нигезе таркалуга сәбәпче була. Кече бизнес вәкилләренең юлында еш очраучы күп күләмдәге "беренчел чыгымнар" – коррупция нәтиҗәсе.

Берләшкән Милләтләр Оешмасы башлангычы белән ел саен 9 декабрь көнне Халыкара коррупция белән көрәш көне билгеләп үтелә. 2003 елның нәкъ шушы көнендә БМОның коррупциягә каршы конвенциясе төзелә. Бу вакыйга Мексиканың Мерида шәһәрендә югары дәрәҗәдәге сәяси конференциядә була. 2003нче елның 1 ноябрендә конвенция БМОның Генераль ассамблеясе тарафыннан кабул ителә һәм, 30 ил тарафыннан расланганнан соң, 2005нче елның декабрендә үз көченә керә. Россия моңа 2006нчы елның мартында кушыла.

Әлеге документ нигезендә аңа кул куйган дәүләтләр ришвәтне, коррупцион керемнәрне "юуны", бюджет средстволарын урлауны уголовный җинаять дип белдерергә тиеш.

2003 елгы конвенция – әлеге рухтагы беренче документ. Структураларның коррумпияләшүе илнең муллыгына зыян салган җирләрдә ул аеруча актуаль.

Ел саен бу көнне дөньяның төрле почмакларында коррупциягә каршы көрәш көненә багышланган демонстрацияләр, семинарлар, конференцияләр үтә.

**Район прокуратурасы.**



Фото – Pixabay.com

# Сатучы хаклымы?

Сорагыз – җавап бирәбез

**– Кибеттән кышкы аяк киеме сатып алдым. Әмма ул кечкенә генә браклы һәм бәясе төшерелеп сатылган булып чыкты. Сатып алуыма үкендем. Кибет аны кире кабул итми. Сатучы хаклымы?**

Газета укучыбызның бу соравына ТР Дәүләт алкоголь инспекциясеТүбән Кама территориаль органы өлкән белгече **Алина Виноградова** җавап бирә:

– "Кулланучылар хокукларын яклау турында"гы РФ Законының 10 маддәсендә әйтелгәнчә, сатучы сатып алучыга товарны дөрес сайлап алуны тәэмин итәрлек кирәкле һәм дөрес мәгълүмат бирергә бурычлы. Товарда җитештерү брагы барлыгын хәбәр итеп, сатучы моны эшләгән. Сату-алу килешүе төзеп, Сез җитешсезлекләре булган товарны билгеле бәя буенча (бәясен төшереп) фактта сатып алырга риза булдыгыз. Шулай булгач, кибет закон нигезендә эшләгән. Кызганыч, әмма җитешсезлекләре (килешүдә күрсәтелгән) булу сәбәпле, Сез товарны кире кайтарып бирә алмыйсыз. Әмма икенче җитешсезлекләр ачыкланса һәм сатып алганда Сезне алар турында кисәтмәгән булсалар, товарны кире кайтарып бирә аласыз. Сүз уңаеннан, кибет сезонлы распродажа оештырса, ягъни сыйфатлы товарны төшерелгән бәядән сатса, андый распродажада алган товарны Сез кайтарып бирергә хокуклы.

# Володядан – шашлык

Аш-су

**Рус Смыловка авылында яшәүче Владимир Усков бик тәмле итеп шашлык әзерли. Бу рызыкны ул сарык итеннән ясый. Рецептын сезгә дә тәкъдим итәбез.**



Лилия Шәймиева фотосы.

Кирәкле ингредиентлар: бер килограмм сарык ите, ярты килограмм чамасы башлы суган, тәменчә кара борыч, тоз, виноград серкәсе, петрушка һәм кинза.

Әзерләү тәртибе: суганны әрчеп, нечкә итеп боҗралап кисәбез. Сарык итен җылымса су белән юабыз да артык зур булмаган кисәкләргә турыйбыз. Кисәкләр зур булмаса, ит тиз һәм тигез, сусыл булып пешәчәк. Тоз һәм борыч салып, итне яхшылап болгатып куябыз. Ул 15 минут эчендә тәмләткечләрне үзенә сеңдереп бетерәчәк.

Маринадны аерым әзерлибез. Моның өчен чиста салкын суга берничә аш калагы виноград серкәсен салабыз. Итне тирән кәстрүлгә салып, өстенә суган боҗраларын түшибез һәм маринадны агызып, савытны капкач белән каплап куябыз. 5-7 сәгать дәвамында кәстрүл суыткычта торсын. Шашлыкны учакта кыздырабыз. Калган маринадны ит өстенә сиптергәләп алсак, аеруча тәмле булачак. Шашлыкны өстәлгә кайнар килеш, кинза һәм петрушка белән бизәп бирәбез. Тәмле булсын!

**Рубриканы Лилия Шәймиева алып бара.**

# Котлыйбыз!



Бу көннәрдә районыбызда яшәүче өлкән буын вәкилләре, тыл һәм хезмәт ветераннары **Хәбирова Нәсиха Фәрвазетдин кызы** (Елгабаш) – 90 яшьлек, **Тимербаева Роза Әхмәтгәрәй кызы** (Мари Буләр) – 85 яшьлек, **Шәрифуллин Рафис Равил улы** (Мөслим), **Мәүлиев Алис Асылгәрәй улы** (Мөслим) – 80 яшьлек, **Гәрәев Нил Әхмәт улы** (Мөслим) – 75 яшьлек, **Төхбәгалиева Тамара Ивановна** (Мөслим), **Хәйруллин Роберт** (Исәнсеф) – 70 яшьлек, **Җәләева Резида Хафазетдин кызы** (Мөслим), **Минһаҗев Назыйф Кәрим улы** (Мәлләтамак), **Ахунова Гөлүзә Галимҗан кызы** (Югары Табын), **Маннанов Фәрит Хәмәй улы** (Тойгелде), **Мөҗипова Фаягөл Габделхәй кызы** (Тойгелде) 65 яшьлек юбилейларын билгеләп үтәләр.

Хөрмәтле юбилярлар! Сезне ихластан истәлекле гомер бәйрәмнәрегез белән тәбриклибез. Сезгә имин тормыш, ныклы сәламәтлек телибез. Якыннарыгызның күңел җылысын, ихтирамын тоеп, кадерхөрмәттә озын гомер кичерергә язсын. Гаиләләрегездә һәрвакыт муллык һәм бәрәкәт булсын.

**Рамил Муллин,**
**район башлыгы,**
**район Советы рәисе.**
**Илгиз Низамов,**
**район ветераннар советы рәисе.**

# Карсыз кышта бакчада

Киңәш

**Пешегү – бакча культуралары, барыннан бигрәк күп карлы районнарда киң таралган төшле җимешле агачларның зарарлануының бер төре. Ул кайрының һәм камбийның үлүеннән гыйбарәт.**

Декоратив үсемлекләрнең күпчелеге һәм җимеш культураларының, декоратив төрләрнең кайберләре, аеруча абрикос, слива, чия каты бирешә. Җиләклеләрдән кайчакта кура җиләге, җир җиләге пешегә. Груша, алмагач, сырганак пешегүгә бирешми диярлек, әмма алар да, аеруча яшь үсентеләр, экстремаль очракларда пешегергә мөмкин.

Кайчакта бакчачылар пешегүнең барлыгы турында белми дә һәм аны туңуга кертә, шунлыктан үсемлекне тагы да каплый төшә (мәсәлән, кар белән) һәм моның белән хәлне тагы да катлауландыра, нәтиҗәдә пешегү килеп чыга. Бу хаталарны җибәрмәү өчен, туңуны пешегүдән аера белергә кирәк.

Туңган очракта беренче чиратта агач кәүсәсе (киселештә ул ачык та, ак та түгел, ә кара төсләрдә) һәм бер, ике еллык үсеш, гомумән ябалдашның өске өлеше үсеше зарарлана. Ябалдашның туңган өлешендә яфраклар вак, үсеш зәгыйфь яки ул бөтенләй юк.

Пешеккәндә иң элек кайры һәм ябалдашның аскы өлешендәге камбий зарарлана, агач, шул исәптән берьеллык үсентедә дә ачык, сәламәт булып кала ала. Ябалдаш өчен вак яфраклар һәм зәгыйфь үсеш яки үсешнең бөтенләй булмавы хас. Яфракларның вакытыннан алда саргаюы хас.

Пешегү белән көрәшүче агротехника алымнары үсү процессларының үз вакытында тәмамлануына, тукымаларның өлгерүенә һәм, нәтиҗә буларак, үсемлекләрне кышка әзерләүгә йогынты ясарга тиеш.

Барлык алымнар арасыннан иң ышанычлысы булып утырту өчен дөрес урынны сайлау тора. Абрикос, сливаның себер сортлары, комлы һәм киез чия сортларын бакчада кар катламы 40 см, чиянең гибрид дала сортларын 80 см артмаган урынга утыртырга киңәш ителә. Кар катламы 100 см җыелган очракта яшь груша һәм алма агачлары өчен пешегү куркынычы арта. Бакчагыз түбәнлектә, артык дымлы урында урнашкан очракта, пешегү хас булган үсемлекләрне утыртудан тыелырга кирәк.

«Коры кыш» пешегү куркынычын киметә. Бу очракта кыш чыгучы үсемлекнең ботагын каргa тиюдән һәм явым-төшемнән саклаучы махсус корылма куялар. Моның өчен, мәсәлән ботак тирәли тимердән яки рубероидтан цилиндр ясап әйләндереп алалар (иске чиләкне файдаланырга мөмкин). Ботак тирәли дүрт тар гына такта кагып чыгарга мөмкин. Бу цилиндрның һәм турыпочмаклыкның өстен чүпрәкләр белән каплыйлар, ә өстенә пленка куеп дым керүдән саклыйлар.



Фото – Pixabay.com

## Кыскача

**Сәламәтлек**

Җирлегебездә яман шеш авырулы райондашларыбыз аз түгел. Бүген 63 кеше шундый исемлектә тора. Аларның күбесендә – эчәклек һәм үпкә рагы. “Үлемгә китерүче авырулар исемлегендә онкология беренче урында тора. Узган ел әлеге авырудан 58 кеше якты дөнья белән хушлашса, быел бу күрсәткеч 63 кешене тәшкил итә. Авыруны иртә диагностикалау бик кыен. Вакытында дөрес ярдәм күрсәтелсә, онкология авыруларын да җиңеп булыр иде”, – ди онкология кабинеты шәфкать туташы Дилбәр Шабаева.

**Иминлек**

1 декабрьдән “Алкоголь – 2020” профилактик операциясе старт алды. “Бу чара алкоголь базарында хокук бозуларны кисәтү һәм гражданнарның спиртлы суррогатлар белән агулану очракларын булдырмау максатыннан үткәрелә. Операция барышында Яңа Усы авылында көмешкә белән сату итүче бер райондашыбыз тоткарланды. Аңа 10 мең сумга кадәр штраф яный. Ялган аракы белән агуланып, район хастаханәсенә эләгүчеләр дә бар. Үзегезне суррогат аракы белән агуламагыз. Ялган аракы белән сату итүчеләр турында белсәгез, кичекмәстән район эчке эшләр бүлегенә хәбәр итегез”, – ди җинаятьләрне эзләү бүлеге җитәкчесе Булат Җамалиев.

**ДАИ**


Узган атнада Игенче авылыннан 1979 елгы райондашыбыз, юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозып йөргән өчен саллы гына штрафка тартылды. “Мөслимнең Пушкин урамында ДАИ хезмәткәрләренә туктамыйча, әлеге райондашыбыз башта өч мәртәбә Мөслимне әйләнде, аннары Сарман ягына юл тотты. Качкан вакытта ул участок инспекторының машинасын бәрде, өч мәртәбә светофорның кызыл утына чыкты, өч мәртәбә җәяүлегә юл бирмәде, машина утын сүндереп чапты, каршы як полосага чыкты, авария урынын калдырып китте һәм башкалар. Күпсанлы кагыйдә бозуларны исәпләп, әлеге ир-егетнең 20 мең сумга якын штрафы җыелды. Моңа өстәп, исерек килеш транспорт белән идарә иткәне өчен аңа ел ярымнан өч елга кадәр машина йөртү таныклыгыннан мәхрүм ителү һәм 30 мең сум штраф та яный. Исерек шоферны Сарман районының Рантамак авылында тоткарладык. “Лада-Гранта” машинасы бәрелеп беткән иде. РФ Административ хокук бозулар кодексының 13.9 маддәсе буенча беркетмә төзелеп, әлеге ир-егет сак астына алынды”, – дип хәбәр итә ДАИның өлкән инспекторы Феликс Мәгъданов.

**Рубриканы Лилия Шәймиева алып бара.**

# Үткәннән бер мизгел



Һөнәри училищеда. 1980 еллар. Фотоны Мөслим авылыннан Рәзинә Исламова тәкъдим итте.



Тормыш юлларымда очрап, язмышымны үз кулларына алган, матур гаилә корып, барыбыз өчен кинәшче, ярдәмче булган кадерлебез **Хәсәншин Дамир Яхъя улының** 9 декабрьдә – юбилее.

Кадерлебез, юбилееӊ белән котлап, аяз көннәр, яхшы кәеф, ныклы сәламәтлек телибез. Алдагы гомер юлың сөенечле вакыйгаларга бай, тормышыбыз имин һәм бәрәкәтле булсын!

*Без телибез сиңа теләкләрнең*
*Иң изгесен һәм иң олысын.*
*Тоеп яшә һәрчак тормышыңда*
*Һәрберебезнең күңел җылысын.*

**Тормыш иптәшең Әлфия, кызларың-кияүләрең, оныкларың.**

# Котлыйбыз!

***

Яңа Сәет авылында туып-үскән, хәзер Мөслим авылында яшәүче **Мәүлиев Алис Асылгәрәй улы** 80 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Дөреслек һәм гаделлек өлгесе булган Алис Мәүлиев гомере буе җаваплы эшләрдә хезмәт куя. Ул 25 ел буе Яр Чаллы шәһәренең социаль яклау идарәсен җитәкли.

Сабыр холыклы, киң күңелле, һәркемгә игътибарлы бабабызның оныкларын тәрбияләүдә дә өлеше зур. Матур итеп рәсем ясау, кул эшләре белән шөгыльләнү оныкларына да бирелгән.

Кадерле кешебез! Сине 80 яшьлек юбилееӊ белән котлыйбыз. Сәламәтлек, күңел тынычлыгы, хәерле озын гомер телибез. Балаларыңның кадер-хөрмәтен күреп, әниебез белән тигез гомер итәргә язсын сезгә.

**Иң изге теләкләр белән әниебез, балалар, оныклар, кода-кодагыйлар, туганнар.**

***

Исәнсеф авылында яшәүче кадерле әтиебез **Хәйруллин Роберт Хәйрулла улының** 9 декабрьдә – 70 яшьлек юбилее.

Кадерле әтиебез, сине гомер бәйрәмең – юбилееӊ белән чын йөрәктән тәбрик итәбез. Алдагы тормышыңда сәламәтлек, җан тынычлыгы, әни белән якыннарыңның җылысын тоеп, куанычлы, бәрәкәтле гомер итүеңне телибез. Безгә, балаларыңа, олы терәк, оныкларыңа кадерле бабай булып бергә-бергә яшәргә язсын.

**Иң изге теләкләр белән балаларың, оныкларың һәм әниебез дә кушыла.**

***

Хөрмәтле мөслимлеләр!

Татарстан Республикасы хәрби комиссариаты, Сарман һәм Мөслим районнары хәрби комиссариатының шәхси составы һәм үз исемемнән Ватан геройлары көне белән котлыйм. Бу көн ныклы рух, ватанпәрвәрлек, ихтыяр көче, кыюлык һәм эшсөярлекне, Ватан мәнфәгатьләре өчен үз-үзеңне корбан итүгә әзерлекне гәүдәләндерә. Россия герое дигән мактаулы исемне йөртүче – һәркем өчен үрнәк. Без арабызда геройлар яшәвен белергә тиеш.

**Дажгын Гассанов, Сарман һәм Мөслим районнары хәрби комиссары.**

**“Мөслим-информ”га татар һәм рус телләрен яхшы белүче корреспондентлар кирәк. Т. 2-55-00, 8-9172785533.** Реклама

*БУ УРЫНДА СЕЗНЕҢ БЕЛДЕРҮ БУЛЫРГА МӨМКИН ИДЕ!* Реклама

# Кышның сихри мизгелләре





Флүн Вилданов фотолары.

## Кар ява

Соргылт мамык төсле көн,
Йоп-йомшак дымык һава.
Умарта аерган төсле,
Чәбәләнеп, кар ява.

Тыныч йокла, газиз җирем,
Язгы җилләр уятыр.
Бизәкләнгән яшел күлмәк
Кояшкай алып кайтыр.
Ләйсән яңгыры юдырыр,

Чәй эчерер, коендырыр.
Саба җилләр чәчләреңне
Назлап кына тарап торыр.

**Фәссах Вилданов.**

**Требуются**

**– ветеринарный врач**
**– управляющий СП Мазино Малая**
**– агроном**
**– специалист по охране труда**
**– инженер (сельхозтехника)**
**– инженер-механик**

**Телефон 89172227288**
AhmetzyanovaLK@Chelny-hleb.ru

Реклама

**ТЕПЛИЦЫ**
от производителя
ДОСТАВКА
УСТАНОВКА
ГАРАНТИЯ
ДУГИ 40х20 от 20 000 руб.
8-917-258-94-29 8-937-590-56-85
Реклама

**НАЛИЧНИКИ**
из цветного металла
от **2000** руб.
Широкий ассортимент.
КОЛПАКИ, ПАРАПЕТЫ,
ДОБОРНЫЕ ЭЛЕМЕНТЫ,
ВОДОСТОЧНЫЕ СИСТЕМЫ
и др.
***Замеры бесплатные!***
Реклама
Тел.:**89375283405, 89375222132**

**КАЗ МАМЫГЫ**
***САТЫП АЛАМ.***
**Т.8-987-416-64-06.**
Реклама

**ХӘТЕР ТАШЛАРЫ, ЧАРДУГАННАР.**
**Фәтхуллин ур., 6.** Ялсыз эшлибез.
**Т.2-38-46, 8-927-451-27-10.** Реклама

**ОЧКИ ОПТИЧЕСКИЕ**
**± 0,5 до ±10,0**
*«Магнит», 2 этаж. Т.8-987-274-27-05.*
ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА.
Реклама

## Реклама

### Сатыла

**терлек, кош-корт**

- **Йомырка тавыклары,** әтәчләр, яңа катырылган казлар. Т.8-987-414-07-86, 8-900-323-04-83.
- **Бозаулар.** Т.8-960-079-78-44, 8-937-777-20-88.

**төзелеш материаллары**

- **Жом, гравий, щебенка.** Китерәбез. Т.8-937-526-73-78.

**төрлесеннән**

- **Телекарта. Триколор МТС.** Т.8-917-898-29-38. Марат.

### Хезмәт күрсәтәбез

- **Делаем все:** кафель ванной и туалета; выравнивание потолков и стен, обои; стяжка, линолеум, ламинат, наливной пол; декоративная штукатурка; установка межкомнатных дверей; гипсокартон. Т.8-937-592-73-90.
- **Ремонт холодильников,** стиральных машин. Т.8-917-895-15-54, 8-927-476-86-86.

### Сатып алам

- **КРС мясом.** Т.8-917-435-41-04.
- **Терeләй мал.** Т.8-917-435-41-04.
- **Сыер ите.** Т.8-963-135-33-71.
- **Үгез, сыер ите.** Т.8-927-966-55-53.
- **Сыер, үгез:** итләтә, терелэй. Т.8-987-135-03-47, 8-927-940-31-01.

## Бу кызыклы

**Аккошта 25000нән артык каурый бар**

Казлар каракҗиләк ярата.

Дельфиннарның ярты баш мие генә йоклый. Икенче яртысы бу вакытта әйләнә-тирәне күзәтә.

Диңгез мәчеләре 2 сәгать суламыйча тора ала.

Крокодиллар телен чыгара алмый.

Алтын балыкның хәтере 3 секундлык кына.

Җилкәнле балык иң җитез. Аның тизлеге 115 км/сәг. җитә ала.

Диңгез кысласының йөрәге башында урнашкан.

Гигант кальмарның күзе баскетбол тубы кадәр бар. Кешеләр аны фотога төшерүгә 2006 елда гына ирешә. 500 килограммлы кальмарлар су төбендә 200 метрдан 1 километрга кадәр тирәнлектә яши.

Император пингвиннары 500 метр тирәнлеккә чума һәм 18 минут сулыш алмый тора ала.

Зәңгәр китның аврылыгы 3 филнеке кадәр. Дөньядагы иң зур хайван да – зәңгәр кит.

Акчарлаклар тозлы су эчә ала.

Еланнар күз кабагы аша күрә.

Әкәм-төкәм тоташ 3 ел йоклый ала.

**Кешенең борыны гомер буе үсә**

Безнең тәндә дөньядагы барлык кешеләр санынын да күбрәк күләмдә организмнар яши.

Кеше курыкканда яхшырак күрә башлый.

Олы яшьтәге кеше тәнендәге нервларның озынлыгы 75 километрга якын.

100 төрлэдән артык вирус борынга тому төшүнең сәбәпчесе булырга мөмкин.

Әгәр дә кешенең бер борын тишеге 72 сәгать дәвамында суламаса, тәсләр аеру сәләте югала башлый, сулый башлауга ул функция кире кайта.

Балалар яз көне тизрәк үсүчән.

**Гамәлгә куючы: “ТАТМЕДИА” АҖ.** **www.muslumirc.ru** **Реклама хезмәте телефоны: (85556) 2-43-05.**

Авыл утлары
Мөслим районы газетасы
“ТАТМЕДИА” АҖ филиалы директоры – баш редактор **Р. Р. Афзалова.** Тел.: 2-55-00.

**Редакция адресы:** 423970, Татарстан, Мөслим районы, Мөслим авылы, Пушкин ур., 43.
**Электрон адрес:** muslimau@rambler.ru
**Телефоннар:** бухгалтерия – 2-39-76, реклама, заказлар – 2-43-05.
**Газетаның оештыручысы һәм нәшире:** "ТАТМЕДИА" АҖ. 420097, Казан шәһәре, Академическая ур., 2.

Газета элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникация сферасында күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсендә ПИ №ТУ16-01027 номерлы таныклык белән 2013 нче елның 16 маенда теркәлде.
Газета “Глагол” ҖЧҖ басылды.
Адресы: 423800, ТР, Яр Чаллы шәһәре, Әлмәт тракты, 10 йорт, 3 бина.
Басарга кул куелды 08.12.2020, график буенча – 19.00, фактта – 17.00.
«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

ТАТ МЕДИА
**Тираж – 2301 данә.**

Редакция фикере һәрвакытта да авторлар фикере белән аваздаш булмаска мөмкин.
Редакциянең рәсми оешмаларда яклаучы булу мөмкинлеге юк.
**Кулъязмаларга бәяләмә язылмый һәм алар кире кайтарылмый.**
Реклама-игъланнардагы мәгълүматның дөреслеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы.
© Материаллар редакциянең язма рөхсәте белән генә күчереп бастырылырга мөмкин.
Газета татар телендә атнага ике тапкыр – чәршәмбе һәм җомга көннәрендә, рус телендә атнага бер тапкыр – җомга көнне чыга.
Заказ №2546.
Язылу индексы – П9418.
Бәясе ирекле.
16+